**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.01.2025 Балык Бистәсе штп. № 03 пи

2025 елда балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү" дәүләт программасын раслау турында" 05.03.2019 №158 карарын гамәлгә ашыру максатларында карар бирәм:

1.Расларга:

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне;

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия составын;

"2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру" муниципаль программасын;

балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында оператив мәгълүмат формасын.

2. "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге" муниципаль казна учреждениесенә, "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы мәгариф оешмалары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

2.1) ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның; инвалид балаларның; физик һәм (яки) психик үсештәге кимчелекләре булган балаларның; кораллы һәм милләтара конфликтлар, экологик һәм техноген бәла – казалар, табигый бәла – казалардан зыян күргән, качаклар һәм күченеп китәргә мәҗбүр булган балаларның; экстремаль шартларда калган балаларның; көчләү корбаннары булган балаларның; тәрбия колонияләрендә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтүче балаларның; үз-үзен тотышы девиант (иҗтимагый куркыныч) булган, махсус белем бирү оешмаларында тәрбияләнүче балаларның, тәрбия, укыту һәм махсус педагогик якын килүне таләп итүче укучыларның; килеп туган хәлләр нәтиҗәсендә тормыш рәвеше объектив бозылган һәм әлеге шартларны мөстәкыйль рәвештә яисә гаилә

ярдәмендә җиңә алмаган балаларның; җан башына уртача керемнәре яшәү минимумыннан түбән булган, «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә бирелә торган айлык пособие алучылар булып торучы гаиләләрдә тәрбияләнүчеләрнең; социаль реабилитацияләүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган оешмаларда тәрбияләнүчеләрнең; социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балаларның (алга таба-авыр тормыш хәлендә булган балалар) ялын беренче чиратта оештырырга;

2.2) Мәгариф оешмаларының лагерьларында, шулай ук Татарстан Республикасы шәһәр яны лагерьларының профильле сменаларында асрамага бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларның ялын оештырырга;

2.3) һөнәри югары белем бирү оешмалары студентларын практика узу чорында балалар сәламәтләндерү оешмалары эшенә җәлеп итәргә;

2.4) балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыручы республика профильле сменаларына сәләтле балаларны, волонтерларны, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активистларын, укуда, иҗатта, спортта ирешкән казанышлары һәм балалар һәм яшьләр хәрәкәтендә актив катнашканары өчен Кара диңгез буендагы лагерьларга бүләк сыйфатында җибәрелә торган республика, бөтенроссия, халыкара конкурслар, ярышлар һәм олимпиадалар җиңүчеләрен һәм призерларын сайлап алырга һәм тупларга;

2.5) "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Дельфин» спорт-сәламәтләндерү комплексы" муниципаль бюджет учреждениесе, "Балык Бистәсе агротехника техникумы " урта һөнәри белем бирү дәүләт автоном белем бирү учреждениесе, мәктәпләрнең спорт заллары һәм спорт мәйданчыклары базаларында физкультура-массакүләм эшләр үткәрергә;

2.6) Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгына караган ял оешмаларында профильле сменаларга юлламалар алган балалар турында мәгълүматны социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – ЕГИСО) биреп барырга;

2.7) 2025 елга календарь планы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы беренчелекләре, команда ярышлары һәм спорт-массакүләм чаралар үткәрергә.

3."Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

3.1) контракт системасы турында законнарда билгеләнгән тәртиптә, республика сәламәтләндерү оешмалары сменаларына (шул исәптән профильле) җибәрелә торган балаларга юлламалар сатып алу өчен сатулар нәтиҗәләре буенча билгеләнә торган муниципаль контрактлар төзү;

3.2) республика сәламәтләндерү оешмалары сменаларына (шул исәптән профильле) җибәрелә торган балаларга юлламалар сатып алу өчен төзелгән

муниципаль контрактлар буенча финанслау һәм акчаларны үз вакытында күчерү (торглар нәтиҗәләре буенча билгеләнә);

3.3) балаларның ялын оештыруны мониторинглау һәм методик ярдәм күрсәтү:

- белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган лагерьларның сменаларында;

- белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган хезмәт һәм ял лагерьларында;

- 2025 елның 1 маеннан 31 августына кадәр белем бирү оешмалары белән берлектә «Куркынычсыз җәй-2025" операциясен үткәрү;

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе базасында мәгариф оешмасы оештырган көндезге лагерьларда эшләүче кадрларны укыту;

-белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге (мәктәп яны), вакытлыча (кыска вакытлы) лагерьларда балаларга өстәмә белем бирүне оештыру;

- хезмәт һәм ял лагерьлары сменаларында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру (җәйге ял);

- лагерьларның (мәктәп яны һәм ЛТО) сменаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү;

- балаларның ялын оештыру вакытында хезмәтне саклау кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тоту;

- сәламәтләндерү оешмаларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;

- сәламәтләндерү оешмаларында санитар норма һәм кагыйдә таләпләрен үтәү;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе белән берлектә белем бирү оешмалары оештырган лагерьларга, көндезге хезмәт һәм ял лагерьларына юллама алган авыр тормыш хәлендә калган балалар, муниципаль һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең балалары, коммерция һәм коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан тыш) балалары турында ЕГИССОга мәгълүмат бирү эше алып бару.

4. "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге" муниципаль казна учреждениесенә тәэмин итәргә:

4.1) контракт системасы турында законнарда билгеләнгән тәртиптә, авыр тормыш хәлендә калган балалар, шулай ук профилактик учетта торучы балалар өчен, сәламәтлек саклау оешмаларына махсуслаштырылган республика сменаларына җибәрелә торган, сату нәтиҗәләре буенча билгеләнә торган сәламәтләндерү оешмаларына җибәрелә торган юлламалар сатып алуга муниципаль контрактлар төзүне;

4.2 авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен, шулай ук профилактик учетта торучы, махсуслаштырылган республика сменаларына сәламәтлек саклау оешмаларына җибәрелә торган балалар өчен төзелгән муниципаль контрактлар буенча акча средстволарын үз вакытында финанслау һәм күчерүне.

5.Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе районнарындагы территориаль бүлегенә тәкъдим итәргә:

5.1) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 №248-ФЗ Федераль законы таләпләренә туры китереп, көндезге белем бирү оешмалары оештырган лагерьлар сменаларын, көндезге белем бирү оешмалары оештырган хезмәт һәм ял лагерьлары сменаларын эксплуатацияләүне үз вакытында күзәтү.

6. «Татарстан Республикасында гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Лаеш районындагы бүлегенә тәкъдим итәргә:

6.1) түләү алмыйча:

-ялны оештыруның гамәлдәге санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килү-килмәүгә санитария-эпидемиология экспертизасы;

-ял оешмаларына эшкә җибәрелүче персоналны гигиеник укыту һәм профилактик медицина тикшерүләр уздыру, аларны ачу алдыннан лаборатор-инструменталь тикшеренүләр үткәрү, шулай ук гельминтозларга тикшеренүләр уздыру (йомырка, глист, лямблий цисты һәм энтеробиоз анализы), эчәк инфекцияләре йоктыручыларны ачыклау, корсак тифына канны серологик тикшерү, эчәк инфекцияләрен йоктыручыларны ачыклау буенча тикшеренүләр үздыру;

-сәламәтләндерү оешмалары ачылыр алдыннан, аларны Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсе һәм аның территориаль бүлекләре күрсәтмәләре нигезендә, дәүләт йөкләмәсе кысаларында дератизация һәм акарицид эшкәртүләрнең нәтиҗәлелеген тикшерү;

6.2) төзелгән граждан-хокукый килешүләр нигезендә:

балалар һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру эше барышында балаларның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өчен лаборатор-инструменталь тикшеренүләр;

6.3) бөер синдромлы геморрагик бизгәкне профилактикалау максатларында сәламәтләндерү оешмалары ачылыр алдыннан белем бирү оешмалары белән дератизация чараларын үткәрүгә килешү төзергә;

6.4) талпан энцефалитын, боррелиозны профилактикалау максатларында акарицид эшкәртүне уздыруга, эшкәртүнең нәтиҗәлелеген тикшереп торуга шартнамә төзергә.

7. Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлегенә түбәндәгеләрне тәэмин итүне тәкъдим итәргә:

7.1) балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру, шулай ук аларны сәламәтләндерү өчен билгеләнгән объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан саклануына карата таләпләрнең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

7.2) мәктәп яны, хезмәт һәм палатка лагерьлары хезмәткәрләренең хөкем ителүе яисә җинаять эзәрлекләве фактлары булу-булмавын тикшерү;

7.3) мәктәп яны, хезмәт һәм палатка лагерьлары хезмәткәрләренең коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә гамәлдәге закон таләпләрен үтәвен контрольдә тоту.

8.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетында каралган акчалар, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр хисабына 2025 елда балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру чыгымнарын финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә. Акча нисбәте 99% республика һәм 1% район хисабына булырга тиеш.

9.«Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә тәкъдим итәргә:

9.1) балигъ булмаганнарны укудан һәм каникулдан буш вакытларында вакытлыча эшкә урнаштырганда, шулай ук ял итү оешмаларында балалары белән бергә ял итүче ата-аналарга медицина тикшерүләрен түләү алмыйча оештырырга;

9.2) Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2020 елның 31 декабрендәге 1420н номерлы "Башкарганда мәҗбүри башлангыч һәм периодик медицина тикшерүләре (тикшерү) үткәрелә торган зарарлы һәм (яки) куркыныч җитештерү факторлары һәм эшләр исемлеген һәм авыр эшләрдә һәм зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары белән эшләүче хезмәткәрләргә мәҗбүри башлангыч һәм периодик медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрү тәртибен раслау турында"гы боерыгы таләпләренә туры китереп, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга бүлеп бирелә торган акчалар хисабына, түләү алмыйча, ялны оештыруга җәлеп ителгән персоналны сезонлы тикшерүне тәэмин итәргә

9.3) ялны оештыруга җәлеп ителә торган персоналны сезонлы карау кысаларында түләүсез флюорография тикшерүе уздыруны тәэмин итәргә.

9.4) территориаль принцип буенча дәвалау-профилактика оешмаларының медицина хезмәткәрләре көче белән көндезге ял һәм хезмәт лагерьлары сменаларында, хезмәт һәм ял лагерьлары сменаларында балаларны һәм яшьләрне медицина хезмәте белән тәэмин итүне гамәлгә ашырырга;

9.5) медицина хезмәткәрләренең санитар-агарту эше планына сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәү, балигъ булмаганнар арасында алкоголизм, наркомания һәм токсикоманияне профилактикалау буенча мәгълүмати-агарту чараларын кертергә;

9.6) «Балалар» (озата бармыйча) яки «Ана һәм бала» (әти-әни, законлы вәкил озатуында) юлламалары буенча хроник авырулары булган 4 яшьтән 17 яшькә кадәрге балаларны, шул исәптән авыр тормыш хәлендә калган балаларны шифаханәдә дәвалануны оештырырга;

9.7) ЕГИССОга шифаханә-курорт оешмаларына юлламалар алган балалар турында мәгълүмат бирү эшен тәэмин итәргә.

10. Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең күзәтү эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсенең Алексеевск һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары буенча районара бүлегенә һәм ФГКУ «Татарстан

Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 7 отряды» ФГКУның 128 нче янгын-коткару бүлегенә тәкъдим итәргә:

10.1) һәр смена ачылыр алдыннан сәламәтләндерү оешмаларының янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры килү-килмәүне ачыклау максатыннан, комплекслы тикшерү оештырырга;

10.2) балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру чорында сәламәтләндерү оешмаларында һәм массакүләм ял итү урыннарында янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне күзәтүне тәэмин итәргә.

11.«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы киноучреждениесе» муниципаль бюджет учреждениесенә каникуллар чорында балалар һәм яшьләр өчен киносеанслар, мультфильмнар күрсәтүне оештыруны тәэмин итәргә.

12.«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы Балык Бистәсе районының «Авыл офыклары» газетасына массакүләм мәгълүмат чараларында 2025 елгы сәламәтләндерү кампаниясенә әзерлек һәм аны үткәрү барышын яктыртуны тәкъдим итәргә.

13."Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль заказ хезмәте" муниципаль казна учреждениесенә тәэмин итәргә:

13.1) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан сәламәтләндерү оешмаларына юлламалар сатып алу өчен муниципаль ихтыяҗларга сатып алуларны гамәлгә ашыруны;

13.2) балалар һәм яшьләрнең ялы белән бәйле контрактлар реестрына кертү өчен муниципаль контрактларны һәм шартнамәләрне, аларны алган көннән, өч көнлек (эш көннәрендә) срокта карарга.

14. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге” муниципаль казна учреждениесенә оештырырга:

14.1) сәламәтләндерү лагерьларында күчмә китапханәләр;

14.2) сәламәтләндерү лагерьларында истәлекле һәм тарихи даталарга багышланган чаралар үткәрүне.

15.«Сетевая компания» ААҖ филиалы Балык Бистәсе РЭСына белем бирү оешмалары оештырган җәйге лагерьларны электр энергиясе белән өзлексез тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

16. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының 2025 елда балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы барлык милек формасындагы оешмаларына, учреждениеләренә тәкъдим итәргә:

16.1) медицина персоналын эшкә алуның килешү формасын күздә тотарга;

16.2) Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын, җирле бюджет акчаларын файдалану турында финанс хисапларын төзелгән шартнамәләр, муниципаль контрактлар нигезендә вакытында тапшыруны тәэмин итәргә.

16.3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенә тапшырырга:

2025 елның 1 апреленә кадәр-барлык типтагы лагерьларны ачу графикларын;

2025 елның 1 июненнән, әлеге карарга кушымта нигезендә, сәламәтләндерү лагерена кергәннән соң өч көнлек срокта (эш көннәре исәпләнә) балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында оператив мәгълүматны;

2025 елның 1 августына кадәр - үткәрелгән чаралар турында фото һәм видеоматериаллар тупланган иҗади отчетларны.

17.2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссиягә:

17.1) күзәтчелек органнары катнашында балалар лагерьларын сәламәтләндерү сезонына кабул итүне оештырырга;

17.2) контрольдә тотарга:

-массакүләм ял итү урыннарында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләренең үтәү өчен ведомство куркынычсызлык службалары белән берлектә медик-санитар хезмәт күрсәтүне һәм җәмәгать тәртибен саклауны;

-һәр смена ачылыр алдыннан, сәламәтләндерү оешмаларында санитар кагыйдәләрнең, янгын куркынычсызлыгы таләпләренең, суда кеше тормышын саклау кагыйдәләренең, хезмәткәрләрнең хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклау таләпләренең үтәлешен, ял итүчеләрнең куркынычсызлыгын тикшерү максатыннан комплекслы тикшерүне оештыруны;

-сәламәтләндерү оешмаларының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар комплексын эшләү һәм гамәлгә ашырылуын. Электр җиһазларының торышына, янгын сүндерү автоматикасы җайланмаларының һәм янгын турында кешеләргә хәбәр итү системаларының, телефон элемтәсенең, беренчел янгын сүндерү чараларының булуына һәм төзеклегенә, шулай ук янгын чыккан очракта хезмәт күрсәтүче персоналның нәрсә эшләргә кирәклеген белүләренә аерым игътибар бирергә кирәк;

-сәламәтләндерү оешмалары җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәтне саклау буенча укуларын үткәрү, шулай ук хезмәтне саклау буенча инструктажлар үткәрүне.

18. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

19. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А. К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы Башкарма
комитетының 13.01.2025 №03пи
карары белән расланган

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия (алга таба - Комиссия) җирле үзидарә органнарының үзара килешеп эшләүләрен тәэмин итү һәм аларның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы территориаль органнары һәм балаларның, яшьләрнең ялын оештыру өлкәсендәге оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында оештырылган орган булып тора.

2.Комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль норматив хокукый актларга һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы территориаль органнары, балалар һәм яшьләрнең ялын әзерләү һәм оештыру белән шөгыльләнүче оешмалар белән хезмәттәшлеген оештыру;

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча оешмалар, предприятиеләр, учреждениеләр эшчәнлеген анализлау, комиссия утырышларында аларның эшчәнлеге турында мәгълүматны тыңлау, үз вәкаләтләре чикләрендә тәкъдимнәр һәм карарлар кабул итү, аларның үтәлешен тикшерү;

-балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру һәм финанслау мәсьәләләрен карау;

-«2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру» муниципаль программасын гамәлгә ашыруны контрольдә тоту.

4. Комиссия хокуклы:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләргә һәм кертергә;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләрдән аның компетенциясенә караган документларны, белешмәләрне, материалларны соратып алырга;

балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының үтәлешен мониторинглауны тормышка ашырырга.

5.Комиссия Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына балалар һәм яшьләрнең ялына бүлеп бирелгән акчалардан файдалану турында хисап бирә.

6.Комиссия составы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

7. Комиссияне рәис җитәкли, аның бер урынбасары билгеләнә.

Комиссия рәисе аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, комиссия утырышларын алып бара, комиссиянең эш планын раслый. Комиссия рәисе булмаганда аның вәкаләтләрен комиссия рәисе урынбасары башкара.

8. Комиссия составына шулай ук комиссия сәркатибе да керә.

Комиссия сәркатибее Комиссия утырышларын әзерләү эшен оештыруны һәм комиссия утырышларында кабул ителә торган карарларның үтәлешен мониторинглауны гамәлгә ашыра. Комиссия эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча сәркатип комиссия рәисе һәм аның урынбасары йөкләмәләрен үти

9. Комиссия составына шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты бүлекләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы оешмалары, предприятиеләре, учреждениеләре вәкилләре дә керә.

10. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру мәсьәләсе буенча кабул ителгән комиссия карарлары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының барлык җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районындагы территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы оешмалары, предприятиеләре, учреждениеләре тарафыннан үтәлергә тәкъдим ителә.

11.Комиссия үз эшчәнлеген аның утырышларында кабул ителә һәм комиссия рәисе тарафыннан раслана торган эш планнарына туры китереп башкара.

12.Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Утырышның көн тәртибен һәм аларны уздыру тәртибен комиссия рәисе билгели.

13.Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

14. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы затларның күпчелек тавышы белән кабул ителә, утырыш

беркетмәләре белән рәсмиләштерелә, аларны комиссия рәисе имзалый. Тавышлар саны тигез булганда комиссия рәисе яисә комиссия утырышында рәислек итүче комиссия рәисе урынбасарының тавышы хәлиткеч булып тора.

Татарстан Республикасы
Балык_Бистәсе муниципаль
районы Башкарма
комитетының 13.01.2025
№03пи карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Вафина А.К. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе |
| Садыков И.М. | "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары |
| Галиуллина Н.С. | «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балалар иҗат үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениясе педагог -оештыручысы, комиссия сәркатибе |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Вильчинская Д.Ю. | “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге” муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазифаларын башкаручы |
| Ногманова И.М. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Садриев Ф.Ф. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге башлыгы, полиция подполковнигы (килешү буенча) |
| Әхмәдиев И.М. | "Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы (килешү буенча) |
| Карпова И.Н. | Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе районнарында территориаль бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Габдрахманов М. Т. | «Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе районнарында филиалы баш табибы (килешү буенча) |
| Ещев О.Л. | Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМның күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсенең |

| | |
|---|---|
| | Алексеевск һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары буенча районара күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Шәфигуллин А.Г. | «Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 128 янгын часте " ФДКУ начальнигы (килешү буенча) |
| Быльнова Е.В. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы сәркатибе |
| Вәлиуллин З.Р. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Муниципаль заказ хезмәте» МКУ директоры |
| Баһаветдинова Г.М. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы |
| Иминова Р.Г. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры |
| Газизова Г.Х. | "ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры - «Авыл офыклары" район газетасы баш мөхәррире вазифаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Җамалиев Р.Б. | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Дельфин «спорт-сәламәтләндерү комплексы» муниципаль бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Кәримуллина Л.В. | "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге" муниципаль казна учреждениесе башлыгы |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 13.01.2025 №03пи карары белән расланган

## "2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру" Муниципаль программасы

### ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | "2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру" (алга таба – Программа) |
| **Программаның муниципаль заказчысы-координаторы** | "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе |
| **Муниципальные заказчики Программы** | "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе;<br>"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге" муниципаль казна учреждениесе |
| **Программаны төп эшләүчеләр** | "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" муниципаль казна учреждениесе;<br>"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге" муниципаль казна учреждениесе |

| | |
|---|---|
| **Программаны төп үтәүчеләр** | “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе;<br>"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге" муниципаль казна учреждениесе;<br>“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни өлкә бүлеге” муниципаль казна учреждениесе;<br>“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Балалар иҗаты үзәге" муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе;<br>"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «ФОРПОСТ» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәпләр) оешмалары үзәге" муниципаль бюджет учреждениесе;<br>"Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы (килешү буенча);<br>«Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе районнарында филиалының Балык Бистәсе бүлеге (килешү буенча);<br>Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлеге (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМның күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсенең Алексеевск һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары буенча районара күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге (килешү буенча);<br>"Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 7 нче отряды ФДКУ"ның 128 нче янгын-коткару бүлеге;<br>"ТАТМЕДИА» АҖ филиалы - «Авыл офыклары" район газетасы (килешү буенча). |
| **Программаның максатлары** | Шәхеснең белем алуга иҗади потенциалын үстерүне тәэмин итү, сәламәтлекне саклау һәм ныгыту, авыруларны профилактикалау, организмны чыныктыру, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыру, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау, иҗтимагый файдалы һәм җитештерүчән хезмәт, физик культура, спорт, туризм белән шөгыльләнү. |

| | |
|---|---|
| **Программаның бурычлары** | Балалар һәм яшьләр ялының, туризм һәм спортның төрле формаларын үстерү;<br>сәләтле һәм талантлы балаларны барлау, фән олимпиадаларында, иҗади конкурсларда җиңүчеләргә ярдәм итү системасын формалаштыру; ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга ярдәм итү;<br>балалар авыруын һәм инвалидлыкны профилактикалау;<br>балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау;<br>авыр тормыш хәлендә булган балаларны җәмгыятьтә интеграцияләүне һәм нәтиҗәле комплекслы социаль яклауны формалаштыру;<br>мәктәп яшендәге балаларны каникул чорында ял белән тәэмин итү;<br>балаларны һәм яшьләрне ел дәвамында (каникул чорыннан тыш) ял белән тәэмин итү;<br>имин булмаган балаларның проблемаларын хәл итү һәм тормыш хәлен яхшырту;<br>ял оешмаларын персонал белән комплектлауны тәэмин итү. |
| **Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары** | 2025 ел. |
| **Программаны финанслау чыганаклары һәм күләмнәре** | 2025 елга Программаны финанслауның гомуми күләме 5836,20 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>ялны оештыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр-5331,9 мең сум;<br>Татарстан Республикасы бюджетыннан предприятиеләр һәм оешмалар хезмәткәрләренең балалар ялын тәэмин итүгә субсидияләр -0 мең сум;<br>авыр тормыш хәлендә булган балаларның ялын оештыруга субсидияләр-446,2 мең сум;<br>ата-аналар акчасы- 0 мең сум;<br>районның җирле бюджетыннан-58,4 мең сум.<br>Искәрмә: финанслау күләмнәре фаразланган характерда һәм җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, төзәтмәләр кертелергә тиеш |
| **Программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы** | Программаның үтәлешен «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге» муниципаль казна учреждениесе белән берлектә гомуми контрольдә тота, планлы һәм максатчан күрсәткечләрне төгәлләштерә, программа үтәлешенең барышы турында җыелма мәгълүматны туплый. |

| | |
|---|---|
| **Ірограммань гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре** | Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру, сәламәтләндерүнең нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле шартлар тудыру;<br>7 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балаларның гомуми саныннан кимендә 50 процентын каникул вакытында төрле ял формалары белән колачлауны тәэмин итү;<br>патриотик юнәлештәге чаралар белән мавыгучы балалар һәм яшьләр санын арттыру, хәрби-спорт лагерьларында әзерлек узган балалар һәм яшьләр санын арттыру, яшьләрнең рухи-әхлакый культурасын, гражданлык тәңгәллеге дәрәҗәсен күтәрү. |

## I.ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЫ, БУРЫЧЛАРЫ, ЧАРАЛАРЫ, ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУНЫҢ КӨТЕЛГӘН СОҢГЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТАСВИРЛАМАСЫ, АНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ВАКЫТЫ ҺӘМ ЭТАПЛАРЫ

Шәхеснең белем алуга иҗади потенциалын үстерүне тәэмин итү, сәламәтлекне саклау һәм ныгыту, авыруларны профилактикалау, организмны чыныктыру, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыру, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау, аларны иҗтимагый файдалы һәм җитештерүчән хезмәткә, физик культура, спорт, туризм белән шөгыльләнүгә тарту Программаның максаты булып торалар.

Куелган максатка ирешү түбәндәге бурычларны хәл итү юлы белән гамәлгә ашырыла:

балалар һәм яшьләр ялының, туризм һәм спортның төрле формаларын үстерү;

сәләтле һәм талантлы балаларны барлау, фән олимпиадаларында, иҗади конкурсларда җиңүчеләргә ярдәм итү системасын формалаштыру; ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга ярдәм итү;

балалар авыруын һәм инвалидлыгын профилактикалау;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау;

авыр тормыш хәлендә булган балаларны җәмгыятьтә интеграцияләүне һәм нәтиҗәле комплекслы социаль яклауны формалаштыру;

мәктәп яшендәге балаларны каникул чорында ял белән тәэмин итү;

балаларны һәм яшьләрне ел дәвамында (каникул чорыннан тыш) ял белән тәэмин итү;

имин булмаган балаларның проблемаларын хәл итү һәм тормыш хәлен яхшырту;

ял оешмаларын персонал белән комплектлауны тәэмин итү.

Программа чаралары аның максатлары һәм бурычлары, җаваплы башкаручыларны күрсәтеп, программаның 1 нче кушымтасында тәкъдим ителгән.

## II. ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮНЕ НИГЕЗЛӘҮ

2025 елга Программаны финанслауның гомуми күләме 5836,5 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

ялны оештыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр-5331,9 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджетыннан предприятие һәм оешма хезмәткәрләренең балалар ялын тәэмин итүгә субсидияләр-0 мең сум;

авыр тормыш хәлендә булган балаларның ялын оештыруга субсидияләр-446,2 мең сум;

ата-аналар акчасы- 0 мең сум.

Районның җирле бюджетыннан-58,4 мең сум

Искәрмә: финанслау күләмнәре фаразланган характерда һәм җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## III. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Балансларында сәламәтләндерү лагерьлары булган һәм балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының барлык милек рәвешләрендәге оешмалары, учреждениеләре, оешмалары тапшырырга тиеш:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Балалар иҗат үзәге” муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенә:

2025 елның 1 апреленә кадәр-барлык типтагы лагерьларны ачу графикларын;

2025 елның 1 июненнән июленә кадәр сәламәтләндерү лагерена кергәннән соң өч көнлек срокта, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында оператив мәгълүматны;

2025 елның 1 августына кадәр - үткәрелгән чаралар турында фото һәм видеоматериаллар тупланган иҗади отчетларны.

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 25 числосына кадәр программаны тормышка ашыру буенча хисап бирә.

## IV. ПРОГРАММАНЫҢ СОЦИАЛЬ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ

Шәхеснең белем алуга иҗади потенциалын үстерүне тәэмин итү, сәламәтлекне саклау һәм ныгыту, авыруларны профилактикалау, организмны чыныктыру, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыру, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау, аларны иҗтимагый файдалы һәм җитештерүчән хезмәткә, физик культура, спорт, туризм белән шөгыльләнүгә тарту Программаның максаты булып

торалар.

Программаны тормышка ашыруның төп социаль нәтиҗәлелеге түбәндәгеләрдә чагыла:

халыкның балалар һәм яшьләрнең ял итү өлкәсендә сыйфатлы хезмәт күрсәтүләрдән канәгать булу дәрәҗәсен күтәрү, балалар һәм яшьләр арасында авырулар санын киметү;

имин булмаган балаларның тормыш хәлен яхшырту һәм аларның проблемаларын хәл итү;

ятим балаларга, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга ярдәм итү;

балаларны һәм яшьләрне каникул чорында ял белән тәэмин итү.

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре:

7 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балаларның гомуми санынннан кимендә 50 процентын каникул вакытында төрле ял  чаралары белән балаларны колачлауны тәэмин итү;

патриотик юнәлештәге чаралар белән мавыгучы балалар һәм яшьләр, хәрби-спорт лагерьларында әзерлек узган балалар һәм яшьләр санын арттыру;

яшьләрнең рухи-әхлакый культурасы дәрәҗәсен күтәрү;

гражданлык таңгаллеге дәрәҗәсен күтәрү.

"2025 елга Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районында балалар һәм яшьләрнең
ялын оештыру"муниципаль
программасына 1номерлы кушымта

**"2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру" муниципаль программасы кысаларында үткәрелә торган, расланган хезмәт күрсәтү күләмнәренә туры китерелгән чаралар**

| № п/п | Чараның исеме | Уздыру сроклары | Кеше саны | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Җәйге чорда мәгариф оешмасы оештырган көндезге лагерьда балаларны һәм яшьләрне сәламәтләндерү һәм ял сменасын оештыру | 2025 елның июнь, июль айлары | 350 (мәктәп яны) | "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" МКУ |
| 2. | Җәйге чорда мәгариф оешмасы оештырган көндезге лагерьда балаларны һәм яшьләрне сәламәтләндерү һәм ял сменасын оештыру | 2025 елның июнь, июль айлары | 90 (ҖХЛ) | "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" МКУ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3. | Җәйге чорда торглар нәтиҗәләре буенча билгеләнә торган шәһәр читендәге лагерьдагы профильле сменада балаларның ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру | 2025 елның гыйнварыннан һәм калган чорга | 60 (18 көн) | “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” МКУ |
| 4. | Җәйге һәм калган чорда торглар нәтиҗәләре буенча билгеләнә торган шәһәр читендәге лагерьдагы профильле сменада балаларның ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру | 2025 елның гыйнварыннан һәм калган чорга | 90 (7 көн) | “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” МКУ<br>"Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге" МКУ |
| 5. | "Өмет" палатка тибындагы лагерьда балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру. | 2025елның җәйге чорына | 160 (7 көн) | "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге" МКУ |
| 6. | Торглар нәтиҗәләре буенча билгеләнә торган стационар лагерьда авыр тормыш хәлендә калган балаларның ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру. | 2025 елның гыйнвар аеннан калган чорга кадәр | 5 (21 көн) | "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге" МКУ |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7. | Торглар нәтиҗәләре буенча билгеләнә торган стационар лагерьда авыр тормыш хәлендә калган балаларның ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру. | 2025 елның гыйнвар аеннан калган чорга кадәр | 15 (21көн) | "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге" МКУ |
| **Барлыгы:** | | | **770** | |

**МӘГАРИФ ОЕШМАСЫ ОЕШТЫРГАН КӨНДЕЗГЕ ЛАГЕРЬДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ**

**244,27 сум.(шул исәптән бюджет 207,63 сум, ата-ана взносы 36,64 сум)**

| Лагерь оештыру өчен база (мәктәп) | Уздыру территориясе | Кеше саны* | Көннәр саны* | Юлламаның норматив бәясе,сум 5449.08 | Бюджеттан субсидияләр 4631.76 | Ата-ана взносы 817.32 | Башка средстволар (предприятие, җирле бюджет) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Җәйге чорга | | | | | | | |
| "2 номерлы Балык Бистәсе урта гомуми белем бирү мәктәбе" МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 105 | 21 | 572153,80 | 436023,00 | 85818,60 | |
| “Биектау урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 20 | 21 | 108981,60 | 92635,20 | 16346,40 | |
| “Зур Мәшләк урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 17 | 21 | 92634,36 | 78739,92 | 13894,44 | |
| “Күгәрчен урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 30 | | 163472,40 | 138952,80 | 24519,60 | |
| “Котлы Бөкәш урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 44 | 21 | 239759,52 | 203797,44 | 35962,08 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| “Масловка урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 34 | 21 | 185268,72 | 157479,84 | 27788,88 | |
| “Яңа Арыш урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 30 | 21 | 163472,40 | 138952,80 | 24519,60 | |
| “Югары Тегермәнлек урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 35 | 21 | 190717,80 | 162111,60 | 28606,20 | |
| "Корноухово төп белем бирү мәктәбе” МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 10 | 21 | 54490,80 | 46371,60 | 8173,20 | |
| "Шомбыт урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 25 | | 136227,00 | 115794,00 | 20433,00 | |
| **Барлыгы** | | **350** | **21** | **1907178,00** | **1621116,00** | **286062,00** | |

**МӘГАРИФ ОЕШМАСЫ ОЕШТЫРГАН КӨНДЕЗГЕ ХЕЗМӘТ ҺӘМ ЯЛ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ (259,48 сум-бюджет)**

| Лагерь оештыру өчен база (мәктәп) | Уздыру территориясе | Кеше саны* | Көннәр саны* | Юлламаның норматив бәясе,сум 4396,86 | Бюджет-тан субсидия ләр 4396,86 | Ата-ана взносы | Башка средстволар (предпри-ятие, җирле бюджет) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Җәйге чорда (бюджет-**259,48** сум.) | | | | | | | |
| "2 номерлы Балык Бистәсе урта гомуми белем бирү мәктәбе" МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 25 | 18 | 116766,00 | 116766,00 | - | |
| “Зур Мәшләк урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 10 | 18 | 46706,40 | 46706,40 | - | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| “Котлы Бөкәш урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 19 | 18 | 88742,16 | 88742,16 | - | |
| “Күгәрчен урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 10 | 18 | 46706,40 | 46706,40 | - | |
| “Яңа Арыш урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 16 | 18 | 74730,24 | 74730,24 | - | |
| "Шомбыт урта белем бирү мәктәбе” МБМУ | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 10 | 18 | 46706,40 | 46706,40 | | |
| **БАРЛЫГЫ ХЯЛ** | | **90** | **18** | **420357,60** | **420357,60** | | |

## ШӘҺӘР ЯНЫ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА ПРОФИЛЬЛЕ СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ (1223,20 сум)

| Стационар БСЛ исеме | Уздыру территориясе | БСЛ ны баланста тотучы-ның исеме | Кеше саны* | Көннәр саны* | Юлламаның норматив бәясе **22017,60** | Бюджеттан субсидияләр **18714,96** | Ата-ана взносы **3302,64** | Башка средство-лар (предпри-ятие, җирле бюджет) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Ачык торг уздыру нәтиҗәләре буенча (җәйге һәм калган чорга) | | | | | | | | |
| | | | 20 | 18 | 440352,00 | 374299,20 | 66052,80 | |
| | | | 20 | 18 | 440352,00 | 374299,20 | 66052,80 | |
| | | | 20 | 18 | 440352,00 | 315899,20 | 66052,80 | 58400,00 |
| **БАРЛЫГЫ** | | | **60** | **18** | **1321056,00** | **1064497,60** | **198158,40** | **58400,00** |
| Ачык торг уздыру нәтиҗәләре буенча (җәйге һәм калган чорга) | | | | | | | | |
| | | | 20 | 7 | 171245,00 | 196784,70 | 25687,20 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 20 | 7 | 171245,00 | 196784,70 | 25687,20 | |
| | | | 20 | 7 | 171245,00 | 196784,70 | 25687,20 | |
| | | | 30 | 7 | 256872,00 | 218341,20 | 38530,80 | |
| **БАРЛЫГЫ** | | | **90** | **7** | **770616,00** | **655023,60** | **115592,40** | |

## ИҖАДИ СӘЛӘТЛЕ ЯКИ СОЦИАЛЬ АКТИВ БАЛАЛАР ҺӘМ ВОЛОНТЕРЛАР, БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘР ИҖТИМАГЫЙ БЕРЛӘШМӘЛӘРЕ АКТИВЫ ӘГЪЗАЛАРЫ, БАЛАЛАРГА ӨСТӘМӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ ТӘРБИЯЛӘНҮЧЕЛӘРЕ ӨЧЕН ПАЛАТКАЛЫ ЛАГЕРЬЛАРДА СМЕНАЛАР (2025 ЕЛ)

**14047,36 СУМ (ШУЛ ИСӘПТӘН БЮДЖЕТ 1196,26 СУМ, ТУГАН. КЕРТЕМ 211,10 СУМ.)**

| Палаткалы лагерь исеме (оештыручы) | Уздыру территориясе | Кеше саны* | Көннәр саны* | Юлламаның норматив бәясе 11550,49 | Бюджет-тан субсидия-ләр 9817,92 | Ата-ана взносы ** 1732,57 | Башка средстволар (предприятие, җирле бюджет) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| "Өмет»спорт-сәламәтләндерү лагере | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 160 | 7 | 1848078,40 | 1570867,20 | 277211,20 | |
| Барлыгы | | 160 | 7 | 1848078,40 | 1570867,20 | 277211,20 | |

# АВЫР ТОРМЫШ ХӘЛЕНДӘ БУЛГАН БАЛАЛАР ӨЧЕН СТАЦИОНАР ЛАГЕРЬДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ (2025 ел)

**(1274,80 сум)**

| **Стационар БСЛ исеме** | **Уздыру территориясе** | **БСЛ ны баланста тотучы-ның исеме** | **Кеше саны** | **Көннәр саны** | **Юлламаның норматив бәясе 26770,80** | **Бюджетан субсидияләр 26770,80** | **Ата-ана взносы -** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Ачык торг уздыру нәтиҗәләре буенча | | | | | | | |
| Башка сәламәтләндерү учреждениеләре | Татарстан Республикасы | | 15 | 21 | 401562,00 | 401562,00 | - |
| Барлыгы | | | 15 | 21 | 401562,00 | 401562,00 | - |
| **Стационар БСЛ исеме** | **Уздыру территориясе** | БСЛ ны баланста тотучы-ның исеме | **Кеше саны** | **Көннәр саны** | **Юлламаның норматив бәясе 8923,60** | **Бюджетан субсидияләр 8923,60** | **Ата-ана** взносы - |
| | | | 5 | 7 | **44618,00** | **44618,00** | - |
| **Барлыгы** | | | 15 | 21 | **44618,00** | **44618,00** | - |

## СӘЛАМӘТЛӘНДЕРҮ ОЕШМАЛАРЫНДА СМЕНАЛАРНЫҢ ДӘВАМЛЫЛЫГЫ

| **Балалар һәм яшүсмерләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру формасы** | **Сменның дәвамлылыгы, көннәр** |
|---|---|
| Шәһәр яны лагерында смена | 7-21 |
| Шәһәр яны лагерында профильле смена, шул исәптән Кара диңгез яры буенда | 7-18 |
| Палаткалы лагерьда профильле смена | 7-21 |
| Мәгариф оешмасы оештырган көндезге лагерьда смена | 7-21 |
| Хезмәт һәм ял лагерында смена | 18 |
| Санатор-курорт оешмасында смена | 24 |
| Физкультура-сәламәтләндерү чаралары, спартакиадалар, вожатыйлар осталыгы мәктәпләре, иҗади конкурслар, фестивальләр, укыту программалары, балалар һәм яшьләр ялын оештыручыларның форумнар, семинарлар һәм балаларның,яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру кысаларында башка чаралар | 3-18 |

## БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘРНЕҢ ЯЛЫН ОЕШТЫРУГА ФИНАНС ЧЫГЫМНАРЫ НОРМАТИВЛАРЫ

| Балалар һәм яшүсмерләрнең ялын һәм | Финанс чыгымнар | Шул исәптән |
|---|---|---|

| сәламәтләндерүне оештыру формасы | нормативы, 1 кешегә көненә, сум | туклануга, көненә 1 кешегә, сум |
|---|---|---|
| Шәһәр читендәге лагерьда смена | 1223,20 | |
| Шәһәр яны лагерында профильле смена | 1223,20 | |
| Палаткалы лагерьда профильле смена | 1650,07 | |
| Белем бирү оешмасы оештырган көндезге (мәктәп яны) хезмәт һәм ял лагерында смена | 259,48 | 220,56 |
| Санатор-курорт оешмаларында смена | | |

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЮДЖЕТЫННАН БАЛАЛАРНЫҢ ҺӘМ ЯШЬЛӘРНЕҢ ЯЛЫН ОЕШТЫРУНЫ ТӘЭМИН ИТҮГӘ СУБСИДИЯЛӘР

| Күрсәткеч исеме | Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләр суммасы | Чыгымнар нормасы, 1балага сум |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасында муниципаль районның дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре, хуҗалык итүче субъект(муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән тыш) хезмәткәрләре балаларының ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруга ( бер балага) финанс чыгымнары нормативы | 0 | 0,00 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма
комитетының 13.01.2025
№03пи карары белән
расланган

**Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында оператив мәгълүмат отчеты формасы**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының
_______________________________________________ УБМ (ТБМ)

| № | Сәламәтләндерү лагерьларының типлары | Лагерьлар саны, ПДП | | Сменаны үткәрү вакыты (ачылу һәм ябылу даталарын күрсәтергә) | Балалар саны | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | план | фактта | | план | фактта | | |
| | | | | | | 15 яшькә кадәр | 15 яшьтән өлкәнрәк | барлыгы * |
| 1 | Мәгариф оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге лагерьларда сменалар | | | | | | | |
| 2 | Мәгариф оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар | | | | | | | |
| | Барлыгы | | | | | | | |

Балаларның гомуми санынннан * ____________кеше:
1.дәүләтнең аерым кайгыртуына мохтаҗлар, барлыгы ________ кеше.
- ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар - ________ кеше.
- инвалид балалар -_________ кеше.

- аз тәэмин ителгән гаилә балалары - _____ кеше.
- тулы булмаган гаилә балалары - ______ кеше.
- күп балалы гаилә балалары - _____ кеше.
- имин булмаган гаиләләрдәге балалар- ____ кеше.
- качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр гаиләләреннән балалар - ______ кеше.

2. Эчке эшләр органнарында исәптә торучы барлык балалар ______ кеше.

2.1. шуларның лагерьларда сәламәтләндерелде ________ кеше (в %_______), вакытлыча эшкә урнаштырылды ____ кеше.
(в % ______).

3.Эшкә урнаштырылган барлык балалар _______ кеше.
шул исәптән мәшгульлек органнары аша ______ кеше.

4. Шәхсән ата-аналары эшкә урнаштырганнар _____ кеше.

5. Республика профильле лагерьларында ял иттләр (БСЛны, ял урынын һәм датасын күрсәтергә)_______ кеше.

6. Ял йортларында, санаторийларда һ. б., ата-аналары эшли торган оешма линиясе буенча ял иттеләр (БСЛны, ял урынын һәм датасын күрсәтергә) _____ кеше.

7. Күп һәм бер көнлек экскурсияләр һәм турпоходларда булдылар _________ кеше.

**Искәрмә:** сменалар тәмамланганнан соң 3 көн узгач, көндезге ял һәм хезмәт лагерьлары сменалары һәм белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган лагерьларның сменалары эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча ирекле рәвештә язмача хисап.